8. Грамматик биремле диктантлар, изложениеләр язу.

7нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр.

1. Фигыльнең барлык төркемчәләрен һәм аларның лексик - грамматик үзенчәлекләрен, ясалышын белү. Фигыльләргә морфологик һәм өлешчә синтаксик анализ ясый белү.
2. Хәбәрлек сүзләрнең телебездә тоткан урынын, формаларын, кулланылышын белү. Морфологик анализ ясый белү.
3. Бәйлекләр белән теркәгечләрнең сөйләмдәге әһәмиятен, куллану үзенчәлекләрен, аларны төркемләү мәсьәләсен, рус телендәге теркәгечләр белән уртак билгеләрен белү. Морфологик анализ ясый белү.
4. Кисәкчәләрнең сөйләмдә тоткан урынын, мәгънәләре буенча төркемләнүен һәм аларның дөрес язылышын белү. Морфологик анализ ясый белү.
5. Ымлыкларның ясалу үзенчәлекләрен һәм төркемчәләрен белү.
6. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
1. Эш кәгазьләреннән дәрестән тыш чара турында белдерү, бәйрәм белән котлау тексты яза белү.
2. Рәсемгә карап, хикәя язу.
3. Мөстәкыйль һәм ярдәмче сүз төркемнәрен кертеп төзелгән җөмләләрне тәрҗемә итү.
4. Изложениеләр, грамматик биремле төрле типтагы диктантлар язу.

## Укыту предметының төп эчтәлеге

| № | Төп темалар | Сәгать саны | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 6 сыйныфта үткәннәрне кабатлау | 6 | морфология турында төшенчә, исем, сыйфат, сан, алмашлык; |
| 2 | Фигыльләр | 13 | боерык фигыль, боерык фигыльнең зат-сан белән төрләнеше, боерык фигыльләрнең дөрес интонация һәм басым белән кулланылышы,;<br>хикәя фигыль, хәзерге заман хикәя фигыль, хәзерге заман хикәя фигыльнең мәгънәләре, үткән заман хикәя фигыль, үткән заман хикәя фигыльнең мәгънәләре, билгесез үткән заман хикәя фигыль, киләчәк заман хикәя фигыль, билгесез киләчәк заман хикәя фигыль, киләчәк заман хикәя фигыльнең мәгънәләре;<br>шарт фигыль, шарт фигыльнең җөмләдә кулланылышы, шарт фигыльнең теләкне һәм үтенүне белдерү формалары; сыйфат фигыль, сыйфат фигыльнең сыйфат һәм фигыль белән уртак яклары, үткән заман сыйфат фигыль, киләчәк үткән заман сыйфат фигыль; |

# Укыту предметының темаларга якынча бүленеше

| № | Дәрес темасы | Сәг. саны | Дәреснең тибы | Уку-укыту эшчәнлегенең төрләре | Контроль төре | Көтелгән нәтиҗә | Өй эше | Дата План | Дата Факт |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Кабатлау. | | | | | |
| 1 | Б.с.ү. Туган телем – иркә гөлем. | 1 | Катнаш дәрес | Күзәтүләрне язма сөйләмдә бирә белү. Телдән хикәя төзү. Туган телнең бөеклеген һәм матурлыгын ачу. | Хикәя язу. | Бирелгән тема буенча 8 - 10 җөмләдән торган хикәя язу. Телгә ихтирам тәрбияләү. | Хикәя “Туган телем-иркә гөлем” | 2.09. | |
| 2 | Исем. | 1 | Белемнәрне кабатлау | Исем, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, күплек сандагы исемнәр, исемнәрнең килеш белән төрләнеше, тартым белән төрләнеше, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше турындагы белемнәрне актуальләштерү. | | Исем сүз төркемен танып белү, граматик билгеләрен һәм вазифаларын аңлау. Аларны дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. | 25нче күнегү. | 09.09 | |
| 3 | Сыйфат. | 1 | Белемнәрне кабатлау | Сыйфат дәрәҗәләрен, сыйфатларның ясалышын искә төшерү. Сыйфатларга морфологик анализ ясау .Күнегүләр үтәү.. | Тест. | Сыйфат сүз төркемен танып белү, граматик билгеләрен һәм вазифаларын аңлау. Аларны дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. Сыйфатларга морфологик анализ ясый белү. | 36нчы күнегү. | 16.09 | |
| 4 | Сан. | 1 | Белемнәрне кабатлау | Сан турындагы белемнәрне актуальләштерү. Саннарга морфологик анализ ясау. Күнегүләр үтәү. | | Сан сүз төркемен танып белү, граматик билгеләрен һәм вазифаларын аңлау. Аларны дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. Саннарга морфологик анализ ясый белү. | 51нче күнегү. | 23.09. | |
| 5 | Алмашлык. | 1 | Белемнәрне кабатлау | Алмашлык турындагы белемнәрне актуальләштерү. Алмашлыкларга морфологик анализ ясау. Күнегүләр үтәү | | Алмашлык сүз төркемен танып белү, граматик билгеләрен һәм вазифаларын аңлау. Аларны дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. Алмашлыкларга морфологик анализ ясый белү. | 61нче күнегү | 30.09. | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | Рәвеш. | 1 | Белемнәрне кабатлау | Рәвеш турындагы белемнәрне актуальләштерү. Рәвешләргә морфологик анализ ясау. Биремнәрне үтәү. | | Рәвеш сүз төркемен танып белү, граматик билгеләрен һәм вазифаларын аңлау. Аларны дөрес язу һәм сөйләмдә дөрес куллану. Рәвешләргә морфологик анализ ясый белү. | 70нче күнегү | 07.10. | |
| | | 13 | | Фигыль. | | | | | |
| 7 | Фигыль<br>Фигыль нигезе.<br>Фигыльләрнең барлык-юклык формасы. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Фигыль турында билгеләмә.<br>Фигыльләрне эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерүче фигыльләргә бүлү.<br>Биремнәрне үтәү.<br>Фигыльнең башлангыч формасы.<br>Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, нәтиҗә ясау.<br>Фигыльнең барлык-юклык төре.<br>Юклык төрендәге фигыльләрдә басым.<br>Биремнәрне үтәү, тәрҗемә итү, диалогик сөйләм төзү. | | Фигыль сүз төркемен танып белү . Эшне, хәрәкәтне, хәлне белдерүче фигыльләрне аеру.<br>Фигыльнең башлангыч формасын белү.<br>Фигыльнең барлык-юклык төрен аеру. Юклык төрендәге фигыльләрдә басымны дөрес кую. | 77 нче күнегү | 14.10. | |
| 8 | Габдулла Тукай. Исемдә калганнар. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | | | | 18 нче биттәге сорауларга җавап бирү | 21.10. | |
| 9 | Изложение. Б.с.ү. | 1 | Белем күнекмәләрен тикшерү | Өйрәтү төрендәге язма эш башкару. | Изложе-ние. | Тыңлаган текстның эчтәлеген тулы, эзлекле һәм дөрес итеп язу. | Кагыйдәләрне кабатлау | 28.10. | |
| 10 | Затланышлы фигыльләр. Боерык фигыль.<br>Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше.<br>Боерык фигыльләрнең кулланылышы. | 1 | Яңа материал белән таныштыру | Укытучы сүзе, дәреслек белән эш, күмәк рәвештә һәм мөстәкыйль күнегүләр эшләү,танып белү активлыгын үстерү, гомумиләштерү, анализ, нәтиҗә ясау<br>Боерык фигыльләрнең зат-сан белән төрләнүе. Күрсәтмә материаллардан файдалану, нәтиҗә ясау, мисалларга нигезләп ныгыту.<br>Биремнәрне үтәү, нәтиҗә ясау, мисалларга нигезләп ныгыту. | | Боерык фигыльнең мәгънәләрен аера белү.<br>Зат-сан белән төрләндерә белү.<br>Боерык фигыльләрне сөйләмдә дөрес куллану, басымны дөрес куеп уку. | 99нчы күнегү<br>100нче күнегү<br>108нче күнегү | 11.11. | |

